КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 ноябрь г.Казань № 1411

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социомәдәни өлкә һәм сәнгать белгечләренә өстәмә һөнәр белеме бирү (квалификация күтәрү) институты» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет белем учреждениесен үзгәртеп оештыру турында» 2012 ел, 23 февраль, 151 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3 – 7 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 937 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 февраль, 167 нче; 2022 ел, 24 октябрь, 1135 нче; 2023 ел, 5 сентябрь, 1074 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә, 1.3 пункттагы «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан халыклары дуслыгы йорты турында» 2005 ел, 6 декабрь, 567 нче карарының 4 – 7 пунктлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Свияжскның, тарихи кече шәһәр буларак, социаль-икътисадын, экологиясен һәм архитектура-сәнгатен торгызу концепциясенең төп юнәлешләрен раслау турында» 2007 ел, 24 август, 417 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин